РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423026, с. Нариманова, ул. Октябрьская, д.19
Тел./факс: 8-(84345) 4-52-46
Email: Salm.Nur@tatar.ru,
ОКПО 0431263, ОГРН 1021605352515,0 ОКАТО 92246872000
ИНН/КПП 1632001515/163201001, ОКТМО 9264772101

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423026, Иске Әлмәт авылы, Октяр ур, 19 йорт
Тел./факс: 8-(84345) 4-52-46
Email: Salm.Nur@tatar.ru
ОКПО 0431263, ОГРН 1021605352515,0 ОКАТО 92246872000
ИНН/КПП 1632001515/163201001, ОКТМО 9264772101

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Әлмәт авыл җирлеге, Нариманов исемендәге поселок,Урман урамы, 14-нче номерлы йорт янында Нариманов исемендәге поселокның Урман урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2020 елда Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Нариманов исемендәге поселокның торак пункт территориясен төзекләндерү.

2) Нариман авылында чаралар үткәрү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселокның мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов